Республика Татарстан
Совет Альметьевского
сельского поселения
Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районы Әлмәт авыл
җирлеге советы

---

РЕШЕНИЕ
19 ноября 2018 года

КАРАР
№ 29

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның планлы чорына бюджеты турында» карар проекты**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның планлы чорына бюджеты турында» карар проектын кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә.
2. Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.
3. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына бюджеты турында» карар проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем оештырырга:
1. Газизов Данияр Әнвәр улы-төркем җитәкчесе
2. Вәлиәхмәтов Радик Габдрәүф улы-төркем әгъзасы
3. Марданшин Илнар Әдип улы -төркем әгъзасы
4. Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәре язма рәвештә, авторның исем фамилиясе, туган елы, адресы күрсәтелеп , эшче төркемгә түбәндәге адреска җибәрелә: ТР, Сарман муниципаль районы Әлмәт авылы, Ленин урамы, 56а йорт, т. 4-23-76
5. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2019 нчы елга һәм 2020, 2021 нче елларның планлы чорына бюджеты турында " карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2018 елның 7 декабренә 14 сәгатькә билгеләргә.

6. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы депутатлары төзәтмәләрен һәм карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы каравына 2021 елның 12 декабренә кадәр кертергә.
7. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге Советы Рәисе Д. А. Газизов